„ПВХО га ХӘЗЕР“ НОРМАЛАРЫНЫҢ ИКЕНЧЕ БАСКЫЧЫ

ТАТГОСИЗДАТ
КАЗАН 1941

СССР ОСОАВИАХИМЫ ҮЗӘК СОВЕТЫНЫҢ ҺАВА ҺӘМ ХИМИЯ ҺӨҖҮМЕНӘ
КАРШЫ ОБОРОНА ИДАРӘСЕ

„ПВХО га ХӘЗЕР“ НОРМАЛАРЫНЫҢ ИКЕНЧЕ БАСКЫЧЫ

(ПВХО ның икенче баскыч значкистларын-инструкторларын хәзерләү буенча программа һәм методик күрсәтмәләр)

ТАТГОСИЗДАТ
ПОЛИТИК ҺӘМ ОБОРОНА ӘДӘБИЯТЫ СЕКТОРЫ
КАЗАН 1941

„Раслыйм"
СССР Осоавиахимы УС.
председателе
Авиация генерал-майоры
П. Кобелев
1941 нче ел 6 нчы июнь.

ПВХО ИНСТРУКТОРЛАРЫ ХӘЗЕРЛӘҮ ПРОГРАММАСЫ БУЕНЧА СӘГАТЬЛӘР ИСӘБЕ

Тәртип №№	ХӘЗЕРЛӘҮ БҮЛЕКЛӘРЕНЕҢ ИСЕМНӘРЕ	Сәгать саны	ИСКӘРМӘ
	1 нче бүлек		
1.	Хәзерге заман сугышында тылны һава һәм химия һөҗүменә каршы оборонага хәзерләүнең әһәмияте һәм Осоавиахимның бурычлары...	6	
	2 нче бүлек		
2.	Фугаслы һәм осколкалы авиабомбалардан саклану	24	
	3 нче бүлек		
3.	Яндыргыч средстволардан саклану .	23	
	4 нче бүлек		
4.	Агулаучы матдәләрдән саклану . .	29	
	5 нче бүлек		
5.	Махсус техник хәзерлек	54	
6.	Халыкны һава һәм химия һөҗүменә каршы оборонага хәзерләүне оештыру	2	
7.	ПВХО буенча массовый эш	2	
	Барсы	140 сәгать	

СССР Осоавиахимы Үзәк Советының ПВХО идарәсе начальнигы — полковник (КОТЛИНСКИЙ)
1 нче сектор начальнигы—полковник (КАРЦЕВ).

Төп нөсхә белән дөрес:
УС ның ПВХО идарәсенең
1 нче секторы өлкән инспекторы (АГЕЕВ).

„Раслыйм"
СССР Осоавиахимы
ҮС председателе
Авиация генерал-майоры
П. Кобелев.
1941 нче ел 6 нчы июнь.

ПВХО ИНСПЕКТОРЛАРЫ ХӘЗЕРЛӘҮ ПРОГРАММАСЫ

1 БҮЛЕК.

ХӘЗЕРГЕ ЗАМАН СУГЫШЫНДА ТЫЛНЫ ҺАВА ҺӘМ ХИМИЯ ҺӨҖҮМЕНӘ КАРШЫ ОБОРОНАГА ХӘЗЕРЛӘҮНЕҢ ӘҺӘМИЯТЕ ҺӘМ ОСОАВИАХИМНЫҢ БУРЫЧЛАРЫ... 6 СӘГАТЬ.

1. Тема — Хәзерге заман сугышында авиациянең роле 3 сәгать.

Максат — Хәзерге заман сугышы тәҗрибәләреннән чыгып һава һөҗүме средстволары һәм ысуллары белән таныштыру.

Эчтәлек: Хәзерге заман авиациясенең сугышучы илләрнең армиясенә, промышленностена, транспортына һәм халкына зарар китерүдәге роле. Бомбага тотучы һәм истребитель авиациясенең нинди максатка билгеләнеше һәм сугыштагы төп хасиятләре.

Авиация тарафыннан тылга зарар китерү өчен кулланыла торган средстволар турында аңлату.

Авиациянең һөҗүм итү объектларына налет ясагандагы эше һәм бомбага тотуда кулланыла торган ысуллары. Авиадесантлар (планерлар, парашютлар һәм самолетлар белән китереп төшерү).

Занятиеләрне уздыру методы. Хәзерге заман самолетлары модельләрен (чертежлар, фото, рәсемнәрен) һәм аларның тактик-техник мәгълүматлары турында характеристика бирелгән таблицаларны күрсәтеп беседа үткәрү.

Авиациянең хәзерге заман сугышындагы роле 2 нче империалистик сугыш тәҗрибәләреннән мисаллар китереп аңлатыла.

Бомбага тотучы һәм истребитель авиациясенең сугыштагы төп хасиятләре (нинди биеклеккә менә алуы, очу тизлеге, эш итү радиусы, никадәр йөк күтәрүе һәм кораллары) турында уртача мәгълүматлар бирелә.

Авиация тарафыннан тылга зарар китерү өчен кулланыла торган средстволар санап кына чыгылалар һәм макетлар, плакатлар, фото рәсемнәр белән генә күрсәтеләләр. Авиация һөҗүме средстволарының төзелешләре һәм зарарлары турында аңлатма киләчәк занятие темаларында бирелә.

2. тема. Тылда ПВХО оештыру — 3 сәгать.

Максат. Тылда ПВХО оештыру белән таныштыру һәм халыкны ПВХО га хәзерләү буенча Осоавиахимның бурычларын өйрәнү.

Эчтәлек: Тылда ПВО ның әһәмияте һәм бурычлары. Һаваны күзәтү, хәбәр итү һәм элемтә (ВНОС), авиазенит оборонасы (АЗО) һәм һава һөҗүменә каршы җирле оборона (МПВО) ның нинди максатка билгеләнеше һәм средстволары турында аңлату. ПВО пункты оештыру турында аңлату. Шәһәрнең, районның, участокның, кварталның җирле ПВО сының бурычлары һәм организацион структурасы.

Халыкны ПВХО га хәзерләү өлкәсендә Осоавиахим оешмаларының бурычлары.

Занятиеләрне уздыру методы. ПВО пункты оештыру, һәм шулай ук шәһәр, район, участок һәм квартал МПВО сы оештыру схемаларын файдаланып лекция — беседа үткәрү.

ВНОС, АЗО һәм МПВО средстволары белән таныштыру өчен, бу средстволарның макетлары (чертежлары яки рәсемнәре) файдаланылырга тиеш.

Искәрмә: Беренче бүлекне өйрәнеп бетергәннән соң, укучыларга укудан тыш вакытта „һава һөҗүме" исемле кинофильм күрсәтелә.

ИКЕНЧЕ БҮЛЕК.

ФУГАСЛЫ ҺӘМ ОСКОЛКАЛЫ АВИАБОМБАЛАРДАН САКЛАНУ.

24 СӘГАТЬ.

3. Тема. Фугаслы һәм осколкалы авиабомбаларның җимерү эше. 2 сәгать.

Максат. Фугаслы һәм осколкалы авиабомбаларның төзелешен һәм җимерү эшен өйрәнү.

Эчтәлек: Фугаслы бомбаларның нәрсә өчен билгеләнүе, аларның төзелеше, калибрлары һәм җимерү эшләре (бәреп тишүе, һава дулкыны удары, һава сирәкләнү дулкы-

ны удары, осколкаларның җимерү эше, яндыру һәм агулау эшләре).

Бомбаның шартлаткычлары: бик тиз, әкренәйтелгән һәм бик озак вакыттан соң шартлаткычлар (взрывательләр) турында аңлату.

Бомбалар турында аңлату: броняны тишүче, бетонны тишеп керүче, төшкәндә планировать итеп төшүче, каты улап төшүче бомбалар.

Фугаслы авиабомбалар кулланунын тышкы күренешләре.

Осколкалы бомбаларның нинди максатка билгеләнеше, үлчәүләре, төзелешләре һәм җимерү эшләре.

Занятиеләрне уздыру методы. Занятиеләр фугаслы һәм осколкалы авиабомбаларның төзелешләре турындагы макетлар, фото һәм рәсемнәрдән, һәм шулай ук аларның җимерү эшләренең характеры турында аңлатучы схемалар һәм таблицалардан файдаланып үткәрелә.

Бомбаларның җимерү эшләрен сөйләүне, 2 нче империалистик сугышта авиациянең төрле җимерүләрен күрсәткән фото рәсемнәрне күрсәтеп алып барырга киңәш ителә.

4. Тема. Фугаслы һәм осколкалы бомбалардан саклану— 8 сәгать.

Максат: 1. Убежищелар ясалышын һәм качу урыннары итеп подвалларны яраклаштыруны өйрәнү.

2. Тар чокырлар (щельләр) казуны өйрәнү.

Эчтәлек: Авиабомбалардан саклану өчен махсус убежищелар, аларның нинди максатка билгеләнеше һәм алардан файдалану кагыйдәләре. Подвал помещениеләрне авиабомбалардан качып саклану урыннары өчен яраклаштыру ысуллары һәм алардан файдалану кагыйдәләре.

Өсте ачык һәм өсте каплаулы (щельләр) тар чокырлар һәм аларның нәрсә өчен билгеләнешләре. Чокырлар казу өчен урын сайлау. Чокырның урыннарын, аларның юнәлешен билгеләү, кирәкле материаллар һәм инструментларны исәпләү, эш көчен урнаштыру. Чокырларны казу, аларны җиһазландыру һәм алардан файдалану кагыйдәләре.

Халыкның „ВТ“ сигналы буенча убежищеларга, кереп качу өчен яраклаштырылган подвалларга, чокырларга кереп качу тәртибе.

Шартламый калган бомба булганда халыкның аннан ничек сакланырга тиешлеге (куркыныч зона, киртәләү, шул участокны бүлеп алу, халыкның саклану кагыйдәләре).

Занятиеләрне уздыру методы. Тема ике занятиегә бүленә.

1. Убежищелар ясауны һәм подвалларны халык кереп качу өчен яраклаштыру ысулларын өйрәнү........ 2 сәгать һәм

2. Чокырлар казуны өйрәнү — 6 сәгать.

Беренче занятие убежищеда һәм убежище өчен яраклаштырылган подвалда, аларның төзелешен һәм алардан файдалану кагыйдәләрен урында өйрәтеп үткәрелә.

Убежище һәм яраклаштырылган подвал булмаганда, занятиеләр вакытында убежищелар һәм шуның өчен яраклаштырылган подвалларның төзелеше һәм алардан файдалану турындагы макетлар, чертежлар һәм плакатлардан файдаланырга кирәк.

Икенче занятие. Занятиеләр үткәрү өчен махсус сайланган мәйданчыкта (бушлык җирдә, басуда, ишек алдында, яшелчә бакчасында һ. б. ш.) практик занятие сыйфатында үткәрелә.

Ачык һәм өсте ябык чокырлар казу өчен урын күрсәтелә һәм фактта урын сайлана, чокырлар өчен җир үлчәнә, аларның юнәлешләре билгеләнә, казып күрсәтелә һәм беркадәр җиһазландырыла да.

Бөтен җиһазларны тулысынча өйрәнү алдан казылып куелган чокырларда үткәрелә.

5. Тема. Фугаслы бомбалар җимерү ясаганда беренче техник ярдәм күрсәтү — 6 сәгать.

Максат. Күмелеп калу, биналар ишелү һәм җимерелүләр вакытында зарарланучыларга беренче техник ярдәм күрсәтергә өйрәтү.

Эчтәлек. Зарарланучыларның кайда калганлыкларын белү өчен ишелгән һәм җимерелгән урыннарны тикшерү.

Зарарланучылар басылып калган, ишелгән помещениеләргә керү юллары ясау. Алар басылып калган помещениеләргә һава кертү өчен тишекләр ясау. Ишелү куркынычы булган урыннарда киртәләр һәм терәкләр ясау. Күмелеп калган убежищеларны һәм помещениеләрне казып арчуның гади ысуллары, алардан кешеләрне чыгару тәртибе.

Водопровод, канализация, газ белән җылыту челтәре һәм үзәктән ягып җылыту трубалары зарарланганда кичектергесез төзәтү эшләрен үтәү ысуллары. Күмелеп калган урыннарны казу буенча халык башкара торган эшләр, ул эшләрне оештыру һәм җитәкчелек итү.

Күмелеп калган кешеләрне чыгару эшләре вакытында саклык чаралары.

Занятиеләрне уздыру методы. Занятиеләр булуы мөмкин булган җимерелүләр һәм аста күмелеп калуларның характерын урында бер йорт янында күрсәтеп аңлату һәм күмелгән урыннарны казу эшләрен үтәү тәртибен һәм техник ысулларын күрсәтү юлы белән үткәрелә.

Водопровод, канализация, газ һәм электер челтәре һәм үзәктән ягып җылыту системасы зарарланган хәлләрдә аларны һич кичекмәстән төзәтү эшләре алып баруның ысулларын, йортта булган тиешле җиһазлар өстендә практик рәвештә күрсәтелә (водопровод челтәренең зарарланган участокларын туктату, электр челтәрләрен өзү һ. б.).

6. Тема. Фугаслы һәм осколкалы бомбалардан зарарланучыларга врачка кадәр ярдәм күрсәтү — 4 сәгать.

Максат. Зарарланучыларга врачка кадәр ярдәм күрсәтергә өйрәтү.

Эчтәлек. Кул астындагы средстволар һәм жгут ярдәме белән кан агуны туктату алымнары.

Индивидуаль бәйләү пакеты (гражданский һәм хәрби үрнәктәге) һәм аның белән файдалану.

Тәннең һәрбер җирендәге бер яклы һәм үтәли чыккан яраны, бинт, бәйләү пакеты һәм кул астында булган материаллар ярдәме белән бәйләп кую. Сынган урыннарны урнаштырып бәйләү.

Каерылу, бәрелү, өшү, яктырту газлары һәм углерод оксиды белән агуланган хәлләрдә беренче ярдәм күрсәтү. Зарарланучыларны носилкаларга салып, кулга күтәреп һәм кул астында булган средстволар ярдәме белән башка урынга күчерү. Сильвестр һәм Шеффер методлары буенча ясалма рәвештә сулыш алдыру.

Занятиеләрне уздыру методы. Занятиеләр практик рәвештә генә алып барылалар. Моның өчен кирәк булган барлык материаллар (индивидуаль бәйләү пакетлары, бинтлар, сөлгеләр, яулыклар һәм башка средстволар) алдан ук хәзерләнеп куелырга, ә кул астында булган средстволарны укучылар занятиегә үзләре алып килергә тиешләр, занятиеләр белән җитәкчелек итүче бу турыда аларга алдан ук әйтеп куя.

Ярдәм күрсәтү алымнарын практик рәвештә үтәү өчен, җитәкче бөтен укучыларны икешәр кеше итеп бүлеп чыга һәм шуларның берсен алып врачка кадәр ярдәм күрсәтү алымнарын эшләп күрсәтә.

Һәрбер күрсәтелгән алымны барлык укучылар үзләре кабатлыйлар.

7. Тема. Халыкны I нче баскыч „ПВХО га хәзер“ нормаларының беренче нормасы буенча хәзерләү—2 сәгать.

Максат. I нче баскыч „ПВХО га хәзер“ нормаларының беренче нормасы буенча занятиеләр оештыру һәм үткәрү методикасын өйрәнү.

Эчтәлек. 1. Беренче норма темалары буенча занятиеләрне ничек хәзерләргә һәм ничек үткәрергә:

а) занятиеләр уздыру урыннары сайлау һәм хәзерләү (убежище, кереп качу өчен яраклаштырылган подвал, чокыр казу урыны, „күмелеп калган урыннарда эшләү“ өчен объект йорт, врачка кадәр ярдәм күрсәтү буенча занятиеләр үткәрү өчен урын).

б) укыту-күргәзмә пособиеләр хәзерләү (макетлар, модельләр, чертежлар, рәсемнәр, фото).

в) занятиеләрне (чокырлар казу, күмелеп калган кешеләрне казып алу эше һәм врачка кадәр ярдәм күрсәтү өчен) кирәкле материаллар һәм инструментлар белән тәэмин итү, һәм бу эшкә учрежлениеләр, предприятиеләр җитәкчеләрен һәм укучыларны тарту.

2. Беренче норма буенча аерым занятиеләр үткәрүгә инструкторларны хәзерләү.

Занятиенең конспекты һәм аның элементлары.

3. Укучыларга нинди өйрәнү кино-фильмнарын һәм ничек күрсәтергә.

4. Хәзерлек үтүчеләрдән беренче норманы ничек кабул итәргә.

Занятиене уздыру методы: класста беседа үткәрү формасында алып барыла.

8. Тема. Халыкны I нче баскыч „ПВХО га хәзер“ нормаларының беренче нормасы буенча хәзерләү—2 сәгать.

Максат. Укучыларга занятиеләр уздыру практикасын бирү.

Эчтәлек. Беренче баскыч „ПВХО га хәзер“ нормаларының беренче нормасы темалары буенча.

Занятиеләрне уздыру методы. Укучыларның бер группасы белән үзлегеннән занятие үткәрү. Җитәкчелек итүче кеше укучыларның аерым группаларына (5 — 6 кеше), алар занятиеләр үткәрү өчен хәзерләнергә тиешле булган темаларны алдан ук биреп куя һәм занятиенең планын — конспектын ничек төзәргә кирәклеген сөйли.

План — конспект (занятиене оештыру, кирәкле җиһазлар һәм укыту-күргәзмә пособиеләр белән тәэмин итү, һәм шу-

лай ук занятиеләр үткәрүнең методы турындагы план-конспект) һәрбер тема буенча программада бирелгән методик күрсәтмәләргә төгәл туры китереп эшләнергә тиеш.

Занятиене, занятие алдыннан җитәкче билгеләгән 1—2 укучы үткәрә.

Укучылар тарафыннан үткәрелә торган занятие буенча җитәкче җентекле тикшерү уздыра.

Искәрмә: Икенче бүлек буенча укудан тыш вакытта түбәндәге кинофильмнар күрсәтелергә тиеш:

а) 4 нче тема алдыннан — „ОВ“ дан коллектив рәвештә саклану“ һәм „тар чокырлар“ („щели“)

б) 6 нчы тема алдыннан — „Ясалма рәвештә сулыш алдыру“.

ӨЧЕНЧЕ БҮЛЕК.

„ЯНДЫРГЫЧ СРЕДСТВОЛАРДАН САКЛАНУ“ — 23 СӘГАТЬ.

9 тема. Яндыргыч средстволарның җимерү эше. — 3 сәгать.

Максат. Яндыргыч средстволарның төзелешен һәм җимерү эшен өйрәнергә һәм тышкы яну күренешләре буенча аларны таный белергә.

Эчтәлек. Яндыргыч авиабомбаларның һәм башка яндыргыч средстволарның нәрсә өчен билгеләнүләре; аларның төзелеше һәм жимерү эшләре.

Дошманның төрле яндыргыч средстволар куллануы билгеләре; төп яндыргыч матдәләрнең яну һәм җимерү эшләренең характеры.

Занятиеләрне уздыру методы. Яндыргыч бомбаларның (1—5 килограммалы натураль зурлыктагыларының) һәм төрле яндыргыч средстволарның макетларын күрсәтеп беседа үткәрү. Термитның яну характерын күрсәтү. Башка төрле яндыргыч матдәләр белән укучылар имитацияләре (охшатып ясалган күренешләре), фото һәм рәсем буенча танышалар.

10. Тема. Янгынга каршы профилактик чаралар — 4 сәгать.

Максат. Янгын чыгу куркынычын киметү буенча профилактик чаралар куллана белү.

Эчтәлек. Профилактиканың бурычлары. Янгын чыгуның аеруча киң таралган сәбәпләре.

Янгынның җәелүенә сәбәп була торган шартларны бетерү (сквознякларны бетерү, түбә тәрәзәләренә пыяла кую, чарлак ишекләрен бикләү һ. б.), квартираларны, чарлакларны, үтеп йөрү юлларын, баскыч клеткаларын һәм ишек алларын янгыннан саклану кагыйдәләре буенча тоту.

Яндыргыч бомбаларны һәм янгынны сүндерү һәм җәелергә юл куймау өчен кирәкле средстволар белән тәэмин итү. Бу средстволарны бинаның янгын ягыннан аеруча куркынычлырак урыннарына туплау. Пожарный постларны җиһазландыру.

З а н я т и е л ә р н е у з д ы р у м е т о д ы. Занятие, занятие үткәрү өчен сайланган бинаның барлык помещениеләрен йөреп чыгу юлы белән, күренгән җитешсезлекләрне аңлатып, янгын чыгу ягыннан аеруча куркынычлы урыннарны һәм аларда булырга тиешле теге яки бу янгын сүндерү средстволарын күрсәтеп практик рәвештә үткәрелә.

11. Тема. Яндыргыч бомбаларны сүндерү средстволары 3 сәгать.

М а к с а т. Яндыргыч бомбаларны сүндерүнең иң гади средстволарын кулланырга өйрәтү.

Э ч т ә л е к. Су белән сүндерү средстволары: пожарный краннар, гидропульт-костыль һәм гидропульт-чиләк. Аларның төзелешләре, эшләү принциплары, җыю һәм сүтү.

Ут сүндергечләрнең күбеклеләре һәм корылары. Аларның төзелеше, эшләү принцибы, зарядка ясау кагыйдәсе. Аларны саклап тоту һәм карау. Тикшерү һәм яңадан зарядка ясау.

Яндыргыч бомбаларны сүндерү һәм җәелергә юл куймау өчен кул астында булган средстволар (ком, кызыл балчык, көл, ящиклар һ. б.).

Ярдәмче инструментлар (клещилар, көрәкләр, совоклар, чиләкләр, мичкәләр, балталар, ломнар, багорлар, пычкылар, электр чыбыкларын кисү өчен кайчылар, кошкалар) һәм аларның нәрсә өчен билгеләнүләре.

З а н я т и е л ә р н е у з д ы р у м е т о д ы. Занятиеләр эш алымнарын, яндыргыч бомбаларны һәм янгыннарны сүндерү өчен приборлар һәм инструментларны күрсәтү методы белән моның өчен сайланган мәйданчыкта (бу эш өчен кирәкле барлык милек һәм инструментлар тупланган урында) үткәрелә. Аерым приборларның төзелеше турында кирәкле аңлатмалар (ут сүндергечләр, гидропультлар, пожарный краннар) аларны күрсәтү процессында, эш техникасын аңлау өчен кирәкле күләмдә бирелаләр.

12. Тема. Яндыргыч средстволарны һәм алар чыгарган янгыннарны сүндерү — 6 сәгать.

Максат. Яндыргыч средстволарны һәм алар китереп чыгара торган янгыннарны сүндерә белү.

Эчтәлек. Термитлы, фосфорлы, электронлы һәм комбинировать ителгән яндыргыч бомбаларны, һәм шулай ук башка төрле яндыргыч средстволарны сүндерү средстволары һәм сүндерү ысуллары. Помещениеләрдән бомбаларны чыгарып ташлау ысуллары, алымнары һәм средстволары. Бомбаларны суга батыру һәм су сибеп сүндерү. Яндыргыч бомбаларның зарар китерүен чикләү өчен ком куллану (комлы мендәргә өстерәп кертү, ком белән күмү һәм комлы ятак ясау).

Яндыргыч средстволардан килеп чыккан янгыннарны ут сүндергечләр, гидропультлар һәм эчке пожарный краннар ярдәме белән сүндерү. Яна торган сыекчаларны сүндерү. Кеше өстендә яна башлаган киемнәрне сүндерү алымнары.

Төтен тулган һәм яна торган биналарда үзеңне-үзең тоту кагыйдәләре.

Занятиеләрне уздыру методы. Занятиеләр, яндыргыч бомбаларның макетлары, һәм шулай ук янгын сүндерү өчен булган барлык средстволар һәм материаллар урнаштырылган баскыч клеткаларында, чарлакта, моның өчен сайланган мәйданчыкта практик рәвештә үткәрелә. Бөтен эш алымнарын (яндыргыч авиабомбаларны помещениеләрдән чыгарып ташлауны, суга батыру, комлы мендәргә өстерәп кертүне һ. б.) җитәкче күрсәтә һәм укучылар кабатлый баралар. Яндыргыч средстволарны һәм янгыннарны сүндерү һәм зарар китерүен чикләү ысуллары буенча кирәкле аңлатмаларны җитәкче тарафыннан эш алымнарын күрсәткән вакытта бирелә.

13. Тема. Янгыннар вакытында халыкларның куркынычсызлыгын тәэмин итү — 2 сәгать.

Максат. Янгын вакытында милекләрне һәм үз-үзеңне уттан коткару һәм күчерү алымнары белән таныштыру.

Эчтәлек. Караңгы һәм төтен тулган помещениеләрдә калган кешеләрне эзләп табу. Үзеңнең куркынычсызлыгың чаралары. Кешеләрне идән буенча үрмәләп, аяк үрә басып, идән буенча өстерәп, пожарный баскычлар аша алып төшү алымнары. Пожарный баскычлары. Пожарныйлардагы кеше коткару бавы: ул бауны яна торган йортка разведка яса-

ганда, һәм шулай ук кешене коткару һәм үз-үзеңне уттан коткару өчен файдалану. Каробинлы коткару поясы һәм аны ничек куллану. Кресло һәм пожарный төеннәр бәйләү; үз-үзеңне уттан коткарган вакытта бауның башын өй эченә ничек бәйләп калдыру турында.

Занятиеләрне уздыру методы. Занятиеләр, моның өчен сайланган объектта практик рәвештә үткәреләләр, һәм шуның мисалында разведка ясау һәм кешеләрне күчерү тәртибе аңлатыла.

Кешеләрне күчерү, бау белән эш итү, баскычтан файдалану һәм кеше өстендәге яна башлаган киемне сүндерү алымнарын занятие җитәкчесе практик рәвештә күрсәтә.

14. Тема. Пешкән хәлләрдә врачка кадәр ярдәм күрсәтү— 2 сәгать.

Эчтәлек. Пешүнең төрләре. Төрле пешүләр булганда врачка кадәр ярдәм күрсәтү алымнары. Пожар чыккан җирдән кешене аңын югалткан хәлдә алып чыгылган кешеләрне аңына китерү алымнары.

Занятиене уздыру методы. Занятиеләр практик рәвештә алып барыла. Кирәкле материаллар алдан ук хәзерләнеп куелырга тиеш (яки җитәкченең алдан биргән заданиесе буенча занятиегә укучылар тарафыннан алып килена). Пешү хәлләрендә врачка кадәр ярдәм күрсәтү алымнары җитәкче тарафыннан күрсәтелә һәм укучылар тарафыннан кабатлана.

15. Тема. Халыкны I нче баскыч „ПВХО га хәзер“ нормаларының 2 нче нормасы буенча хәзерләү — 3 сәгать.

Максат. 1 нче баскыч „ПВХО га хәзер“ нормаларының 2 нче нормасы буенча занятиеләр оештыру һәм үткәрү методикасын өйрәнү.

Эчтәлек. №№ 7 һәм 8 темалар шикелле ук.

Занятиеләрне уздыру методы. Тема ике занятиедә үтеп бетелә.

Җитәкче беренче занятиедә (бер сәгать) икенче норма темалары буенча занятиеләрне ничек хәзерләү һәм үткәрүне сөйли (беренче тема өчен № 7 темада күрсәткән тәртиптә ук).

Икенче занятие — 2 сәгать (максат — укучыларга икенче норма буенча занятие үткәрү практикасы бирү) № 8 темада күрсәтелгән тәртиптә ук укучылар тарафыннан үткәрелә.

Искәрмә: 3 нче бүлек буенча укудан тыш вакытта түбәндәге кино-фильмнар күрсәтелергә тиеш:

а) 11 нче тема алдыннан — „Утсүндергеч белән файдалана бел“,

б) 12 нче тема алдыннан — „Яндыргыч бомбаларның төзелеше һәм аларны сүндерү“.

ДҮРТЕНЧЕ БҮЛЕК.

АГУЛАУЧЫ МАТДӘЛӘРДӘН САКЛАНУ — 29 СӘГАТЬ.

16. Тема. Боевой агулаучы матдәләр һәм аларның зарар китерү эшләре — 3 сәгать.

Максат. Боевой агулаучы матдәләрне (ОВ) һәм аларның сыйфатларын өйрәнү.

Эчтәлек. Боевой агулаучы матдәләр турында һәм аларның кешеләргә, металларга, тканьнарга, ашамлыкка, суга һәм йорт-җир әйберләренә зарар китерү эшләре турында кыскача мәгълүматлар. Агулау көчен озак саклый торган (стойкий) — (иприт, люизит), һәм агулау көчен озак саклый алмый торган (нестойкий) — агулаучы матдәләр — (фосген, дифосген, хлорпикрин, адамсит, хлорацетофенон, дифенилхлорарсин, синиль кислотасы (цианид) һәм углерод (2) оксиды); аларның тышкы күренеше һәм исләре.

Катнаш ОВ куллану. Газның нинди икәнлеген белү өчен индикаторлы кәгазьләр белән файдалану.

Занятиеләрне уздыру методы. Занятиеләр ОВ имитацияләрен (аларның төрләре һәм исемнәре белән таныштыру) һәм газның нинди икәнен белү өчен индикаторлы кәгазьләр белән файдалану алымнарын күрсәтеп, беседа методы белән алып барыла. ОВ ның агулау көчен озак саклый торган булуын аңлату: пыяла өстенә тамызылган бер тамчы су һәм бер тамчы эфирның парга әйләнүенең төрлечә булуын күрсәтеп төшендерелә.

ОВ ның материалларга, тканьнарга һәм үсемлекләргә зарар китерүен, кара калай кисәге, төсле ткань һәм нинди дә булса үсемлек өстендә хлорның тәэсир итүе мисалында (пыяла банкада хлорлы известь һәм берничә тамчы тоз кислотасы ярдәмендә аерып) күрсәтергә. ОВ ның кеше организмына ничек тәэсир итүе турында, зарарлану симптомнары ничек булуын аңлатып тормыйча, боевой агулаучы матдәләргә (БОВ) характеристика бирү процессында гына төшендерелеп үтелә.

17. Тема. Химия һөҗүме средстволарының зарар китерү эше — 2 сәгать.

Максат. Авиахимбомбаларның төзелешләрен һам зарар китерү характерларын, һәм шулай ук кулланыла торган агулаучы матдәләрне тышкы күренешләре буенча тану ысулларын өйрәнү.

Эчтәлек. Авиахимбомбаларның һәм шулай ук сиптерә торган һәм ампулалы приборлар „СОВ химбомбаларының“(ударный һәм дистанцияле) һәм „НОВ химбомбаларының“ нинди максат өчен билгеләнүе һәм төзелешләре.

Химбомбалар, шулай ук сиптерә торган һәм ампулалы приборлар куллануның тышкы күренешләре.

Агулаучы матдәләрне һавада, аерым урыннарда һәм төрле әйберләргә карап тану ысулы һәм моны эшләгәндә саклык чаралары.

Агулаучы матдәләр белән зарарланган участокларны киртәләү һәм зарарланмаган участоклардан бүлеп алу.

Занятиеләрне уздыру методы. Занятиеләр, авиахимия һөҗүме средстволарының макетлары, шулай ук аларның зарар китерү характерларын аңлата торган чертежлар, фото һәм рәсемнәрдән файдаланып үткәрелә. Зарарланган участокны киртәләү билгеләрен күрсәтү, урында — шартлы рәвештә зарарланган төшне фактта киртәләү юлы белән эшләнә.

18. Тема. Противогазлар һәм алар белән файдалану — 3 сәгать.

Максат. „БН“ һәм „ДП“ противогазлары буенча белемне тирәнәйтү һәм „КИП“ противогазын өйрәнү.

Эчтәлек. Һаваны фильтрлаучы „БН“ һәм „ДП“ противогазлары. Аларның төзелеше һәм эшләү схемалары. Йоткычларның (поглотители), фильтрларның нәрсә өчен хезмәт итүе һәм аларның эше. Противогазның төзеклеген тикшерү.

Противогазның төзек түгеллеген белү һәм противогаз төрлечә бозылган хәлләрдә аннан файдалану методы. Бозык противогазны төзек противогаз белән алмаштыру.

Противогаздан кыш көне файдалану.

Противогазны саклау һәм төзек тоту кагыйдәләре.

Изоляцияли торган противогаз: аның төзелеше, нинди

максат өчен билгеләнүе, эш схемасы һәм файдалану кагыйдәләре.

Занятиеләрне уздыру методы. Противогазның төзелеше, аның эш схемасы һәм агуланудан саклау сыйфатлары турындагы занятиеләрне тирәнәйтү, плакатларда киселеше күрсәтелгән противогазлардан һәм һәрбер укучыда булган противогаздан файдаланып эшләнә.

Бозык противогаз белән файдалану алымнарын өйрәнү, җитәкче тарафыннан шундый барлык алымнарны күрсәтү һәм аларны укучыларның кабатлап барулары методы белән алып барыла, шуның белән бергә, укучыларга мәгълүм булмаган, төрлечә бозылган противогазлардан файдаланыла.

Искәрмә: Противогаз киеп торуга күнегү барлык занятиеләр процессында аерым план һәм расписание буенча үткәрелә.

19. Тема. Тирегә тәэсир итүче агулаучы матдәләрдән индивидуаль саклануның махсус средстволары—3 сәгать.

Максат. Агулаучы матдәләрдән саклану киемен өйрәнү һәм аннан файдалана белү.

Эчтәлек. Агулаучы матдәләрдән саклану киемнәренең нинди максат өчен билгеләнүе һәм төзелеше (комбинезоннар, резина итекләр һәм резина перчаткалар, агулаучы матдәләрдән саклый торган оеклар, накидкалар, алъяпкычлар).

Тирене саклау средстволары белән файдалану кагыйдәләре һәм алымнары. Аларның саклау көчләре. Тирене саклау средстволарын төзек тоту һәм саклау. Төрле температураларда саклау киемен киеп эшләү сроклары.

Занятиеләрне уздыру методы. Занятие практик рәвештә алып барыла. Занятие вакытына һәрбер укучы өчен тирене саклау средстволары хәзерләнгән булырга тиеш.

Алардан файдалану кагыйдәләре җитәкче тарафыннан күрсәтеләләр һәм барлык укучылар шуларны үзләре кабатлап баралар.

Тирене саклау киемнәрен киеп эшләүгә күнектерү һәм үзләшү, киләчәктәге тактик хәзерлек занятиеләре вакытында үткәрелә.

20. Тема. Дегазацияләү средстволары һәм алымнары — 4 сәгать.

Максат. Дегазацияләүче матдәләрне, дегазацияләү приборларын һәм аларны куллану техникасын өйрәнү.

Эчтәлек. Дегазациянең нинди максат өчен кулланылуы һәм дегазацияләү алымнары. Дегазацияләүче матдәләр (хлорлы известь, гипохлорит кальциясе, зәһәр натр, натрий гидросульфиды, аммиак, бакыр һәм тимер купоросы). Эреткечләр (спирт, бензин, керосин). Кайнатып дегазацияләү, кайнар һава һәм ут белән дегазацияләү.

Изоляцияләүче материаллар.

Кул белән дегазацияләү приборлары: ВДП, РДП, иләк — носилкалар, алар турында тактик-техник мәгълүматлар; төзелешләре һәм алар белән эш итү техникасы.

Занятиеләрне уздыру методы. Тема ике занятиедә үтелә.

1 нче занятие — „Дегазацияләүче матдәләр һәм дегазацияләү ысуллары" (2 сәгать), дегазацияләүче матдәләрне һәм эреткечләр үрнәген күрсәтеп беседа ясау методы белән алып барыла.

Дегазацияләүче эретмәләрне хәзерләү практик рәвештә үтәлә.

2 нче занятие — „Дегазация средстволары һәм алар белән эш итү техникасы (2 сәгать) — материаллар белән кулланып практик рәвештә үткәрелә.

21. Тема. Ашамлык продуктларын, суны һәм йорт әйберләрен агулаучы матдәләрдән саклау—1 сәгать.

Максат. Ашамлык продуктларны, суны һәм йорт әйберләрен агулаучы матдәләрдән сакларга өйрәтү.

Эчтәлек: Ашамлык продуктларын, суны һәм йорттагы төрле әйберләрне агулаучы матдәләрдән саклау чаралары.

Һава-химия һөҗүменнән соң ОВ кулланылган районда ашамлык продуктларыннан һәм судан файдалану кагыйдәләре.

ОВ белән агуланган районда үз-үзеңне тоту кагыйдәләре.

Занятиеләрне уздыру методы. Ашамлык продуктларын, суны һәм йорт әйберләрен ОВ дан саклау буенча занятиеләр, саклау савытларын, саклагыч материалларны һәм алар белән файдалану ысулларын күрсәтеп үткәрелә.

22. Тема. Химия разведкасы — 3 сәгать.

Максат. Химия разведкасы алып бару техникасына өйрәтү.

Эчтәлек. Химия разведкасы сумкасы. Аның нинди максат өчен билгеләнүе, төзелеше һәм аның белән файдалану. Химия дозоры һәм ул үти торган бурычлар. Дозорга разведка өчен бурыч куелышы. Химия белән агуланган учакларга разведка ясауны башкару техникасы. Агулаучы матдәләрне (ОВ) тану. Куркынычлы зона чикләрен һәм ОВ парлары таралуын билгеләү һәм билгеләр кую. Разведка нәтиҗәсе турында доклад ясау.

Занятиеләрне уздыру методы. Химия разведчигы сумкасын өйрәнү класста үткәрелә (1 сәгать); җитәкче разведчик сумкасындагы һәрбер әйбер белән файдалану алымнарын күрсәтә, һәм бер үк вакытта аларның нинди максат өчен билгеләнүләрен аңлата бара.

Химия разведкасы ясау техникасы, күрсәткеч һәм практик занятие төсендә — алдан ук сайлап куелган участокта үткәрелә.

Җитәкче ничек эшләүне күрсәтү тәртибендә дозорга бурыч йөкли: дозорның алга ничек хәрәкәт итәргә тиешлеген аңлата һәм, тиешле кереш сүз белән, дозорның саклану средстволарын боевой хәзерлек хәленә кай төштә китерергә тиешлеген, разведка ясау, пробалар алу, чикләрне билгеләү техникасын, разведканың нәтиҗәләре турында доклад ясау өчен кирәгә таба чыгуны һ.б. күрсәтә.

Җитәкче тарафыннан күрсәтелә торган бөтен методлар 2—3 укучы тарафыннан (саклаучы киемнәр киенеп һәм химия разведчигы сумкасын тагып) үтәлә.

23. Тема. Халыкны ОВ белән агуланган участоклардан чыгару — 1 сәгать.

Максат. ОВ белән агуланган участоктан чыгу өчен кул астында булган средстволардан файдаланырга өйрәтү.

Эчтәлек. ОВ белән агуланган районда үзеңне ничек тотарга кирәклеге турында кагыйдәләр. Халыкны чыгару өчен үтү юллары һәм басмалар төзү. Куркынычлы зонадан кул астында булган средстволардан файдаланып үтеп чыгу һәм чыккан чакта һәркемнең үзен-үзе саклау чаралары.

Занятиеләрне уздыру методы. Куркынычлы зонадан халыкны чыгару, шартлы рәвештә куркынычлы зона итеп билгеләнгән җирдә, кул астында булган средстволардан файдаланып практик рәвештә үтәлә. Куркынычлы зонадан чыкканнан соң, кул астында булып агуланылган средстволарны салу кагыйдәләре күрсәтелә һәм соңыннан халыкның үзен ничек тотарга тиешлеге турында аңлатма бирелә.

24. Тема. Агулаучы матдәләр белән агуланганда врачка кадәр ярдәм күрсәтү—3 сәгать.

Максат. ОВ белән агуланганда врачка кадәр ярдәм күрсәтә белү.

Эчтәлек. Тирегә тәэсир итә торган агулаучы матдәләр (иприт һәм люизит) бәлән агулану билгеләре. Химиягә каршы пакетның төзелеше һәм нәрсәдән гыйбарәт булуы. СОВ белән агуланган урыннарны химиягә каршы пакет һәм кул астында булган средстволар ярдәмендә эшкәртү техникасы. Юыну пунктында санобработка үтү тәртибе. Буылдыра торган, гомуми агулаучы һәм башка төрле агулаучы матдәләр белән агулану билгеләре һәм зарарланучыларга врачка кадәр ярдәм күрсәтү. Зарарланучыга противогаз кидерү.

Занятиеләрне уздыру методы. Беседа. ОВ ның кеше организмына тәэсир итүен һәм агулануның билгеләрен аңлату өчен муляжлар, плакатлар фото һәм диапозитивлардан файдаланыла. Җитәкче, врачка кадәр ярдәм күрсәтү алымнарын күрсәтә һәм бу алымнарны барлык укучылар кабатлый баралар.

25. Тема. Халыкны беренче баскыч „ПВХО га хәзер“ нормаларының 3 нче нормасы буенча хәзерләү—3 сәгать.

Максат. I нче баскыч „ПВХО га хәзер“ нормаларының 3 нче нормасы буенча занятиеләр оештыру һәм үткәрү методикасын өйрәнү.

Эчтәлек: 7 һәм 8 нче темалар шикелле үк.

Тема ике занятиедә үтелә.

Беренче занятиедә (1 сәгать) җитәкче өченче норма темалары буенча занятиеләрне ничек хәзерләү һәм үткәрү турында сөйли (беренче норма өчен №7 темада күрсәтелгән шикелле үк тәртиптә).

Икенче занятие—(2 сәгать)—(максат—укучыларга өченче норма буенча занятие үткәрүдә практика бирү)—укучылар тарафыннан №8 темада күрсәтелгән шикелле үк тәртиптә үткәрелә.

26. Тема. Халыкны беренче баскыч „ПВХО га хәзер“ нормасының дүртенче нормасы буенча хәзерләү—3 сәгать.

Максат. I нче баскыч „ПВХО га хәзер“ нормаларының дүртенче нормасы буенча занятиеләр оештыру һәм үткәрү методикасын өйрәнү.

Эчтәлек. 1. Дүртенче норманың 10 һәм 11 нче темалары буенча занятиеләрне ничек үткәрергә.

2. Нормалар кабул итү тәртибе.

3. Нормалар тапшырган кешеләрнең учетын алып бару.

Занятиеләрне уздыру методы. Тема ике занятиедә үтелә.

Беренче занятиене (1 сәгать) житәкче теманың эчтәлеге буенча алып бара.

Икенче занятиене (2 сәгать) укучылар үзләре, №8 темада күрсәтелгән тәртиптә үк үткәрәләр.

Искәрмә. Дүртенче бүлек буенча укудан тыш вакытта түбәндәге кино-фильмнар күрсәтелергә тиеш:

а) 16 нчы тема алдыннан — „Боевой агулаучы матдәләр",

б) 18 нче тема алдыннан — „Химиягә каршы индивидуаль саклану".

в) 21 нче тема алдыннан — „Ашамлыкларны агулаучы матдәләрдән саклый бел".

БИШЕНЧЕ БҮЛЕК

МАХСУС ТАКТИК ХӘЗЕРЛЕК — 54 СӘГАТЬ.

27. Тема. Торак йортта ПВО оештыру — 6 сәгать.

Максат. Торак йорт ПВО сының планын төзәргә өйрәтү.

Эчтәлек. Торак йорт (предприятие, учреждение, уку йорты) ПВО сын оештыру. Торак йортта (предприятиедә, учреждениедә, уку йортында) ПВО буенча хезмәт итүчеләр. ПВО начальнигы үтәргә тиешле эшләр. Торак йортның үз-үзен саклау группаларының нинди максат өчен билгеләнүе һәм аларны оештыру.

Йорт ПВО сы планын төзү. Йортның тыныч вакытта һәм куркыныч туган хәлдә ПВО га хәзерләү; эш күрү планы.

Занятиеләрне уздыру методы. Йорт ПВО сын оештыруны һәм план төзүнең элементларын өйрәнү (ике сәгать вакыт бирелә), йортны ПВО га хәзерләүнең конкрет мисалларында үткәрелә. Калган дүрт сәгать җитәкче биргән задание буенча укучылар тарафыннан мөстәкыйль рәвештә төзелгән ПВО планнарын тикшерүгә бирелә.

28. Тема. Тәртип саклау һәм күзәтү звеносының эше — 9 сәгать

Максат. Тәртип саклау һәм күзәтү звеносы эшен өйрәнү һәм аларны хәзерләү буенча занятиеләр үткәрергә өйрәтү.

Эчтәлек. Звеноның нинди максат өчен билгеләнүе, аны оештыру һәм коралландыру. Тәртип саклау һәм күзәтү постлары; аларны коралландыру һәм алар башкарырга тиешле эшләр.

Куркыныч хәл кертелгәндә һәм шул хәл дәвамында звеноның эш итүе. Звеноның „ВТ“ сигналы буенча һәм агулану учаклары килеп чыкканда ничек эш итүе.

Звеноның эшен төгәлләве һәм кабат налетка хәзерлек.

Занятиеләрне уздыру методы. Тема өч занятиедә үтелә:

1 нче занятие (3 сәгать) — практик рәвештә алып барыла. Җитәкче бу занятиене уку үтелә торган урында алдан ук сайланып куелган йорт территориясендә үткәрә. Звено, шул йортның ПВО планында каралган расчет буенча, укучылар группасы составыннан төзелә.

Звеноның эш итүе куркынычлы хәл кертелү моментыннан алып звеноның эшен төгәлләве һәм зарарлану учагы бер үк төрле булганда кабат налет ясауга хәзерләнүгә чаклы булган вакыт эчендә үтелә.

2 нче занятие (2 сәгать) — практик рәвештә үткәрелә. Җитәкче күрсәтүе буенча алдан ук эшләнеп куелган план белән укучыларның берсе тарафыннан үткәрелә (занятие үткәрү планын барлык укучылар да төзиләр). Звено укучылардан төзелә.

Занятиедә звеноның „ВТ“ сигналы буенча, зарарлану учагы бер үк төрле булганда, бөтен эше үтелә.

Төрле хезмәтләргә билгеләү җитәкче тарафыннан занятие башланыр алдыннан эшләнә.

Занятие тәмам булганнан соң җитәкче звено эшенең ничек үтүен тикшерә һәм звеноның эшенә бәя бирә.

3 нче занятие (3 сәгать) — практик рәвештә үткәрелә. Икенче занятиедәге шикелле үк метод белән, ләкин зарарлану учагы катлаулы булган шартларда үткәрелә.

29. Тема. Пожар звеносының эше — 9 сәгать.

Максат. Пожар звеносының эшен өйрәнү һәм пожар звеносы хәзерләү буенча занятие үткәрергә өйрәтү.

Эчтәлек. Звеноның нинди максат өчен билгеләнүе, аны оештыру һәм коралландыру. Пожар постлары, аларны коралландыру һәм аларның бурычлары. Пожар звеносының резервы һәм аның бурычлары. Куркынычлы хәл кертелгәндә һәм шул хәлнең дәвамында звеноның эш итүе. Звеноның „ВТ“ сигналы буенча һәм берәм-сәрәм зарарлану һәм массовый күләмдә зарарлану учаклары булганда ничек эш

итүе. Пожар звеносының „ВТ“ сигналы буенча җыелуы һәм постларга басуы.

Зарарланган учакта эшләү. Үз-үзеңне саклау группасының башка звенолары белән үзара бәгланып эшләү. Звеноның эшен тәгәлләве һәм кабат налетка хәзерләнү.

Занятиеләрне уздыру методы. Тема һәркайсы өчәр сәгатьлек өч занятиедә, „Тәртип саклау һәм күзәтү звеносының эш итүе“ дигән тема занятиеләре методы белән үк үткәрелә.

Бөтен занятиеләр яндыргыч бомбаларның имитацияләре (ошатып ясалган бомбалары) белән, һәм шулай ук яндыргыч бомбаларны сүндерү һәм яндыруларын чикләү һәм алардан килеп чыга торган пожарларны сүндерү средстволары белән тулысынча тәэмин ителгән булырга тиеш.

30. Тема. Аварияләрне төзәтү звеносының эше — 2 сәгать.

Максат. Аварияләрне төзәтү звеносының эшен өйрәнү һәм аны хәзерләү буенча занятие үткәрергә өйрәтү.

Эчтәлек. Звеноның нинди максат өчен билгеләнүе, звеноны оештыру һәм коралландыру. Звеноның личный составының бурычлары. „ВТ“ сигналы буенча звеноның җыелуы. Звеноның водопровод, канализация, газ һәм электр челтәрендәге гади аварияләрне төзәтү буенча эше.

Занятиеләрне уздыру методы. Беседа.

31. Тема. Химия һөҗүменә каршы саклану звеносы эше — 9 сәгать.

Максат. Химия һөҗүменә каршы саклану звеносының эшен өйрәнү һәм шул звеноларны хәзерләү буенча занятиеләр үткәрергә өйрәтү.

Эчтәлек. Звеноның нинди максат өчен билгеләнүе. Звеноны оештыру һәм коралландыру. Звеноның личный составының бурычлары. Куркынычлы хәл кертелгәндә һәм шул хәл дәвамында звеноның эш итүе. Звеноның „ВТ“ сигналы буенча, бер үк төрле һәм катлаулы зарарлану учаклары килеп чыкканда, ничек эш итүе. Үз-үзеңне саклау группасының башка звенолары белән үзара бәгланып эшләү. Звеноның эшен тәгәлләве һәм кабат налетка хәзерлек.

Занятиеләрне уздыру методы. Тема 3 занятиедә үтелә:

1 нче занятиене (3 сәгать, практик занятие) җитәкче үткәрә. Занятиедә звеноның куркынычлы хәл (УП) буенча, „ВТ“ сигналы буенча, „химик тревога“ һәм зарарлану

учагына химик разведка ясау сигналы буенча эш итүе өйрәнелә.

Разведка мәгълүматлары буенча кирәкле дегазация средстволары һәм дегазацияләүче матдәләрнең расчетын укучылар мөстәкыйль рәвештә эшлиләр, житәкче ул расчетларга соңыннан гына төзәтүләр кертә.

Занятие тәмам булганнан соң житәкче тикшерү ясый.

2 нче занятиене (3 сәгать, практик занятие) беренче занятиенең дәвамы рәвешендә җитәкче үткәрә. Звеноның: зарарлану учагын бетерү эше, эшен төгәлләве һәм кабат налетка хәзерлек эше үтелә.

Занятие тәмам булганнан соң житәкче звеноның эш итүенә тикшерү үткәрә.

3 нче занятиене (3 сәгать, практик занятие) алдан ук эшләнгән план буенча укучыларның берсе үткәрә. Занятиеләр үткәрү планын җитәкченең алдан биргән күрсәтмәләре буенча барлык укучылар да төзиләр.

Звено укучылардан төзелә. Занятиедә звеноның куркынычлы хәл башланудан алып эшен төгәлләвенә кадәр вакыт эчендә нәрсә эшләргә тиешлеге практик эшләп үтелә.

Кемне нинди хезмәткә билгеләү җитәкче тарафыннан занятие башланыр алдыннан эшләнә.

Занятие тәмам булганнан соң җитәкче занятие үткәрүне тикшерә һәм укучыларның эшләренә бәя бирә.

32. Тема. Үз-үзеңне саклау группаларының эше— 19 сәгать.

Максат. Торак йорттагы үз-үзеңне саклау группасының эшен өйрәнү һәм шул группаны хәзерләү буенча занятиеләр үткәрергә өйрәтү.

Эчтәлек. Үз-үзеңне саклау группасының куркынычлы хәл кертелгән чакта һәм шул хәл дәвамында эш итүе. Үз-үзеңне саклау группасының: „ВТ“ сигналы буенча, яндыргыч бомбаларның зарарын бетерү буенча, пожар вакытында, җимерелүләр һәм күмелеп калулар вакытында һәм куркынычлы зона (УЗ) килеп чыккан чакта ничек эш итүе.

Зарарлану учагын бетергәннән соң группаның эшен төгәлләве һәм кабат налетларга хәзерлек алып бару.

МПВО ның участок командалары белән үзара багланыш урнаштыру.

Занятиеләрне уздыру методы. Тема биш занятиегә бүленә.

1 нче занятие (3 сәгать)—„Үз-үзеңне саклау груп-

пасының куркынычлы хәл кертелгәндә һәм шул хәл дәвамында һәм „ВТ“ сигналы буенча эш итүе“.

Занятие практик рәвештә җитәкче тарафыннан алып барыла. Үз-үзеңне саклау группасы укучылар составыннан төзелә.

2 нче занятие (4 сәгать) — „Үз-үзеңне саклау группасының яндыргыч бомбаларның зарарын бетерү һәм алардан чыккан пожарны сүндерү буенча эш итүе“. Занятие практик рәвештә үткәрелә һәм беренче занятиенең дәвамы булып тора. Занятиене җитәкче уздыра. Үз-үзеңне саклау группасы укучылар составыннан төзелә.

3 нче занятие (4 сәгать) „Үз-үзеңне саклау группасының катлаулы зарарлану учагын бетерү буенча эш итүе“.

Занятие практик рәвештә җитәкче тарафыннан уздырыла.

Үз-үзеңне саклау группасы укучылар составыннан төзелә.

4 нче занятие (4 сәгать) — „Үз-үзеңне саклау группасының катлаулы зарарлану учагын бетерү буенча эш итүе“.

Занятие практик рәвештә үткәрелә. Занятиене җитәкче тарафыннан алдан ук бирелгән күрсәтмә буенча төзелгән план белән укучылардан берсе алып бара. (Занятие үткәрү планын барлык укучылар да төзиләр).

Кемне нинди хезмәткә билгеләү җитәкче тарафыннан занятие башланыр алдыннан эшләнә. Занятие тәмам булганнан соң җитәкче занятиенең ничек үткәрелүен тикшерә һәм группа начальнигы, звено командирлары һәм аерым расчетлар һәм аерым кешеләрнең эшенә бәя бирә.

5 нче занятие (4 сәгать) — „Үз-үзеңне саклау группасының катлаулы зарарлану учагын бетерү буенча эш итүе“.

Занятие, дүртенче занятие тәртибендә үк, укучылардан берсе тарафыннан үткәрелә.

Искәрмә: Бишенче бүлек буенча укудан тыш вакытта түбәндәге кино-фильмнар күрсәтелергә тиеш:

а) 27 нче тема алдыннан „Торак йорт ПВО сы“. „Безнең йорт ут яктысын яшерүгә хәзер“ һәм „Торак йортта ут яктысын яшерү“.

б) 28 нче тема алдыннан „Һава тревогасы сигналы“. „Химик тревога сигналы“.

33. Тема. Халыкны һава һөҗүменә һәм химия һөҗүменә каршы хәзерләүне оештыру — 2 сагәть.

Максат. Халыкны ПВХО га хәзерләүне оештыру эше белән таныштыру.

Эчтәлек. „ПВХО га хәзер“ нормаларының беренче баскычы буенча хәзерләү. ПВХО (группа, командалар, отрядлар) төзү. Коллектив нормалар буенча хәзерләү. Үз-үзеңне саклау группалары. 2 нче баскыч ПВХО инструкторлары һәм значкистлары хәзерләү. ПВХО мәктәпләре һәм аларның бурычлары.

Осоавиахимның башлангыч оешмаларында ПВХО секцияләре эше.

Занятиеләрне уздыру методы. Класста беседа алып бару.

34. Тема. ПВХО буенча массовый эш — 2 сәгать.

Максат. ПВХО буенча массовый эшнең формалары һәм методлары белән таныштыру.

Эчтәлек. Масса күләмендә противогаз киеп тренировка ясау; тренировканы оештыру һәм уздыру. Противогаз киеп поход ясау. ПВХО кичәләре. Белешмә өстәлләре һәм консультация пунктлары. Ут яктысын яшерү һәм ПВО сигналлары бирелгәндә үз-үзеңне ничек тоту кагыйдәләре турында халык белән беседалар ясау. Кинофильмнар күрсәтү. Масса-күләм тренировкага өйрәтүләр. Һава һәм химия һөҗүменә каршы оборона буенча ярышлар.

Занятиеләрне уздыру методы — класста беседа алып бару.

СССР Осоавиахимы УС ның ПВХО Идарәсе начальнигы — Полковник КОТЛИНСКИЙ.

ПВХО Идарәсенең 1 нче сектор начальнигы — Полковник КАРЦЕВ.

НОРМЫ
„ГОТОВ К ПВХО“
II СТУПЕНИ

(на татарском языке)

Җаваплы редакторы *И. Исхаков*

Басарга кул куелды 25/VII 1941 ел. Тираж 5070. Басма табак 1½. Табакта 44000 хәреф. Авт. 0,41 табак. ПФ 3594. Заказ № 204. Бәясе 25 тиен.
Басылды Камиль Якуб исемендәге китап фабрикасында.
Казан, Бауман урамы, 19. 1941 ел.

Бәясе 25 тиен